ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЬ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР　　　　ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№_718　　　　«_29» _12____2025г.

ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Торгларда җир кишәрлеген арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 467 номерлы карары белән расланган административ регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 октябрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы «Пространстволы мәгълүматларның милли системасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Торгларда җир кишәрлеген арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 467 номерлы карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3.5.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы бер эш көнен тәшкил итә.»;

1.2. 3.6.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.5. Регламентның 3.6.2-3.6.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.6.2 - 3.6.4 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламент пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы 15 эш көне тәшкил итә, җир кишәрлеге бирелачәк дигән хәбәр басылып чыккан очракта-49 эш көне.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р. Р. Закировка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.В. Шеронов